**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Туймәт авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең
Туймәт торак пунктында

**17 октябрь 2025 ел** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлегенең Туймәт торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Туймәт торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы кар җыю техникасы сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу,

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау** (Туймәт торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге башлыгы И.В. Муртазин